Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

2020 ел 18 нче февраль № 2

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Вакытлыча кар өю
урыннарын билгеләү турында

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны вакытында чистартуны тәэмин итү, елның кышкы чорында Камай авыл җирлегендә территорияне җыештыруны тәртипкә салу һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Елның кышкы чорында карны вакытлыча тоту өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияне билгеләргә:

Камай авылында - авылның төньяк өлешендә урнашкан элеккеге терлекчелек фермасы урынындагы мәйданчык.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм мМенделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы: И.И.Әһлиева